Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

9 февраль 2021 ел № 29

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр кертү турында

(Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы идарәсендә 2021 елның 10 мартында теркәлде № RU165070002021001)

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законга үзгәрешләр кертү, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставының XV бүлеге нигезендә, 2020 елның 1 декабрендә узган халык тыңлауларын исәпкә алып, Әлмәт шәһәре прокуратурасының 2020 елның 12 октябрендәге 1051 номерлы күрсәтмәсен карап тикшергәннән соң

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2011 елның 22 сентябрендәге 116 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына (Әлмәт муниципаль районы Советының 2012 елның 21 июнендәге 202 номерлы, 2013 елның 04 июлендәге 305 номерлы, 2014 елның 02 октябрендәге 398 номерлы, 2014 елның 02 октябрендәге 398 номерлы, 2015 елның 13 мартындагы 450 номерлы, 2016 елның 29 апрелендәге 51 номерлы, 2016 елның 28 декабрендәге 142 номерлы, 2017 елның 27 июлендәге 188 номерлы, 2018 елның 11 маендагы 237 номерлы, 2019 елның 25 мартындагы 282 номерлы, 2020 елның 12 мартындагы 363 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә:

2 Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставындагы үзгәрешләрне Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставындагы үзгәрешләрне теркәгәннән соң «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы 8 өлеше нигезендә үз көченә керә.

5. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставының 6 статьясы 1 өлеше 40 пункты, 6.1 статьясы 24 өлеше 24 пункты, 44 статьясы 1 өлеше 3 тугызынчы абзацы, 44 статьясы 2 өлеше 3 пункты тугызынчы абзацындагы үзгәрешләр, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 22 декабрендәге 445-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә керүне исәпкә алып, 92 статьяның 2 өлешендә 2021 елның 23 мартыннан

барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә, 92 статьясы 2 өлеше «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 44 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 8 декабрендәге 411-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә керүне исәпкә алып, 2021 елның 7 июненнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә, 6.1 статьясы 1 өлеше 25 пункты, 44 статьясы 2 өлеше 3 пункты уникенче абзацы «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 518-ФЗ номерлы Федераль законның үз көченә керүен исәпкә алып, 2021 елның 29 июненнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә, 6 статьясы 1 өлеше 7. 1 пункты, 7 статьясы 1 өлеше 17 пункты, 8 пункт егерме дүртенче абзацы, 44 статьясы 1 өлешенең 11 пункты унҗиденче абзацы «Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге эшчәнлекне камилләштерү өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 22 декабрендәге 454 номерлы Федераль законның үз көченә керүен исәпкә алып, 2022 елның 1 гыйнвареннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башлыгы урынбасары А.А. Зиминга йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Советының 2021 елның
9 февралендәге 29 санлы
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Уставына үзгәрешләр

1. 5 статьяның 1 өлешендә «Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» сүзләрен «Районның җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм район төзелеше эшчәнлеге комитеты» сүзләренә алмаштырырга;

2. 6 статьяның 1 өлеше:
2.1. түбәндәге эчтәлекле 7.1 пункт өстәргә:
«7.1) шәһәр һәм авыл торак пунктларыннан читтә муниципаль районнар чикләрендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү;»;
2.2. 40 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«40) комплекслы кадастр эшләрен башкаруны федераль закон нигезендә оештыру һәм территориянең карта-планын раслау.»;

3. 6.1 статьяның 1 өлешендә:
3.1. 24 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«24) комплекслы кадастр эшләрен башкаруда федераль закон нигезендә катнашу.»;
3.2. түбәндәге эчтәлекле 25 пункт өстәргә:
«25) җирлек территориясендә элек исәпкә алынган күчемсез милек объектларының хокук ияләрен ачыклау буенча чаралар күрү һәм үткәрү, күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен әлеге объектларның хокукка ия булучылары турында белешмәләр җибәрү.»;

4. 7 статьяның 1 өлешен түбәндәге эчтәлекле 15, 16, 17 пунктлар белән тулыландырырга:
«15) участок уполномоченные вазыйфасын биләүче хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына күрсәтелгән вазыйфа хезмәткәре биләгән вакытка торак урыны бирү;
16) алкоголь, наркотик яисә башка токсик исереклек халәтендәге затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру»;
17) муниципаль янгын сагы булдыру.»;

5. 12 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3.1 пункты өстәргә:
«3.1) инициатив проектлар;

6. түбәндәге эчтәлекле 15.1 статья өстәргә:
«15.1 статья. Инициатив проектлар
1. Район яки аның өлешендә яшәүчеләр өчен өстенлекле әһәмияткә ия чараларны гамәлгә ашыру максатларында җирле әһәмияттәге яисә җирле үзидарә органнарына бирелгән мәсьәләләрне хәл итү хокукын район башкарма комитетына инициатив проект кертелергә мөмкин. Инициатив проектларны гамәлгә ашырыла ала торган район территориясенең бер өлешен билгеләү тәртибе район Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.
2. Инициатив проектны кертү инициативасы белән уналты яшькә җиткән һәм

тиешле муниципаль берәмлек территориясендә яшәүче кимендә ун граждан булган инициатив төркем, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары (алга таба - проект инициаторлары) чыгыш ясарга хокуклы. Инициатив төркемнең минималь саны район Советының норматив хокукый акты белән киметелергә мөмкин. Район Советының норматив хокукый акты нигезендә проект инициаторы булу хокукы шулай ук район территориясендә эшчәнлек алып баручы башка затларга да бирелергә мөмкин.

3. Инициатив проектта түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

1) муниципаль берәмлек халкы яисә аның өлеше өчен өстенлекле әһәмияткә ия проблеманы тасвирлау;

2) күрсәтелгән проблеманы хәл итү буенча тәкъдимнәрне нигезләү;

3) инициатив проектны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәсен (көтелгән нәтиҗәләрен) тасвирлау;

4) инициатив проектны гамәлгә ашыруга кирәкле чыгымнарның расчеты;

5) инициатив проектны гамәлгә ашыруның планлаштырыла торган сроклары;

6) әлеге проектны гамәлгә ашыруда кызыксынучы затларның планлаштырыла торган (мөмкин булган) финанс, мөлкәт һәм (яисә) хезмәт катнашуы турында белешмәләр;

7) инициатив түләүләрнең планлаштырылган күләменнән тыш, әлеге акчаларны инициатив проектны гамәлгә ашыруга куллану күздә тотылган очракта, җирле бюджет акчалары күләмен күрсәтү;

8) район территориясенә яисә аның чикләрендә инициатив проект гамәлгә ашырылачак өлешен район Советының норматив хокукый актында билгеләнгән тәртип нигезендә күрсәтү;

9) район Советының норматив хокукый актында каралган башка белешмәләр

4. Инициатив проект район Башкарма комитетына кертелгәнче гражданнар җыелышында яисә конференциясендә, шул исәптән территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча гражданнар җыелышында, конференциясендә, инициатив проект турында фикер алышу, аның шәһәр яки аның өлешенең мәнфәгатьләренә туры килүен, инициатив проектны гамәлгә ашыруның максатка ярашлылыгын билгеләү, шулай ук инициатив проектны хуплау турында гражданнар җыелышы яисә конференциясе тарафыннан карар кабул итү максатларында каралырга тиеш. Шул ук вакытта, гражданнарның бер җыелышында яисә бер конференциясендә берничә инициативалы проект каралырга мөмкин.

Район Советының норматив хокукый акты белән гражданнарны сораштыру, аларның имзаларын җыю юлы белән инициатив проектка ярдәм итү мәсьәләсе буенча гражданнарның фикерләрен ачыклау мөмкинлеге каралырга мөмкин.

Инициатив проектны район Башкарма комитетына керткәндә проектның инициаторлары аңа тиешенчә беркетмә, җыелыш яисә конференция, гражданнардан сораштыру нәтиҗәләре һәм (яисә) район халкы тарафыннан инициативалы проектны хуплауны раслаучы имзалар кәгазьләрне беркетә.

5. Инициатив проектны район Башкарма комитетына кертү турындагы мәгълүмат, инициатив проект район Башкарма комитетына кертелгән көннән алып өч эш көне эчендә басылып чыгарга (халыкка җиткерергә) һәм муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән белешмәләр, шулай ук проектның инициаторлары турында информация урнаштырылырга тиеш. Бер үк вакытта гражданнар район Башкарма комитетына үзләренең тәкъдимнәрен, аларны тәкъдим итү срогын күрсәтеп хәбәр итә, ә ул биш эш көненнән дә ким була алмый. Үз искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен уналты яшькә җиткән шәһәр халкы җибәрергә хокуклы. Район Башкарма комитеты күрсәтелгән мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру мөмкинлеге булмаган очракта, күрсәтелгән мәгълүмат муниципаль районның рәсми сайтына куела.

6. Инициатив проект аны керткән көннән алып 30 көн эчендә район Башкарма комитеты тарафыннан мәҗбүри каралырга тиеш. Инициатив проектны карау нәтиҗәләре буенча район Башкарма комитеты түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) инициатив проектны хупларга һәм аның өстендә эшне җирле бюджет турындагы карар белән каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә, җирле бюджет проектын төзү һәм карау тәртибенә ярашлы максатларга һәм (яисә) тәртиптә дәвам итәргә;

2) инициатив проектны хуплаудан баш тартырга һәм инициатив проектны хуплаудан баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, аны проект инициаторларына кире кайтарырга.

7. Район Башкарма комитеты түбәндәге очракларның берсендә инициатив проектны хуплаудан баш тарту турында карар кабул итә:

1) инициатив проектны кертүнең һәм аны карауның билгеләнгән тәртибен үтәмәү;

2) инициатив проектның федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары, башка норматив хокукый актлар, район Уставы таләпләренә туры килмәве;

3) җирле үзидарә органнарының кирәкле вәкаләтләре һәм хокуклары булмаганлыктан, инициатив проектны гамәлгә ашыру мөмкинлеге булмау;

4) инициатив түләүләре барлыкка килмәгән инициатив проектны гамәлгә ашыру өчен кирәкле чаралар күләмендә җирле бюджет акчалары булмау;

5) инициатив проектта тасвирланган проблеманы нәтиҗәлерәк хәл итү мөмкинлеге булу;

6) инициатив проектны конкурс сайлавын узмаган дип тану.

8. Район Башкарма комитеты әлеге статьяның 7 өлеше 5 пунктында каралган очракта проект инициаторларына бергәләп инициатив проектны эшләп бетерергә тәкъдим итәргә, шулай ук аны башка муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы яисә дәүләт органы карамагына аларның компетенцияләре нигезендә тәкъдим итәргә тиеш.

9. Инициативалы проектларны тәкъдим итү, кертү, фикер алышу, карау, шулай ук аларны конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү тәртибе район Советы тарафыннан билгеләнә.

10. Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар исәбеннән финанс ярдәме алу өчен тәкъдим ителә торган инициатив проектларга карата белешмәләр составына таләпләр, инициатив проектларны карау тәртибе, шул исәптән аларны хуплаудан баш тарту өчен нигезләр, мондый инициатив проектларны конкурс нигезендә сайлап алу тәртибе һәм критерийлары Татарстан Республикасы законы һәм (яисә) башка норматив хокукый акты нигезендә билгеләнә. Бу очракта әлеге статьяның 3, 6, 7, 8, 9, 11 һәм 12 өлешләрендәге таләпләр кулланылмый.

11. Район Башкарма комитетына берничә инициативалы проект кертелгән очракта, шул исәптән эчтәлеге буенча шундый ук өстенлекле проблемаларны тасвирлап, район Башкарма комитеты конкурс нигезендә сайлап алуны оештыра һәм бу хакта проектның инициаторларына хәбәр итә.

12. Инициатив проектларны конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү коллегиаль органга (комиссиягә) йөкләнә, аны формалаштыру һәм аларның эшчәнлеге район Советы тарафыннан норматив хокукый акт белән билгеләнә. Коллегиаль органның составы район Башкарма комитеты тарафыннан төзелә. Бу чакта коллегиаль орган әгъзаларының гомуми санының яртысы район район Советы тәкъдимнәре нигезендә билгеләнергә тиеш. Проектның инициаторларына һәм аларның вәкилләренә конкурс нигезендә сайлап алуны уздырганда коллегиаль орган

тарафыннан инициатив проектларны карауда катнашу һәм алар буенча үз позицияләрен бәян итү мөмкинлеге тәэмин ителергә тиеш.

13. Проект инициаторлары, район территориясендә яшәүче гражданнар, гражданнар җыелышы яисә конференциясе тарафыннан вәкаләтләр бирелгән башка гражданнар, шулай ук Россия Федерациясе законнары белән билгеләнә торган башка затлар инициатив проектны Россия Федерациясе законнарына каршы килми торган рәвешләрдә гамәлгә ашыруны җәмәгать контролендә тотарга хокуклы.

14. Инициатив проектны район Башкарма комитеты тарафыннан карау, инициатив проектны гамәлгә ашыру барышы, шул исәптән акчаларны куллану, аны гамәлгә ашыруда кызыксынучы затларның мөлкәти һәм (яисә) хезмәт катнашуы турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) һәм урнаштырылырга тиеш. Инициатив проектны гамәлгә ашыру йомгаклары турында район Башкарма комитеты хисабы инициатив проектны гамәлгә ашыру тәмамланган көннән алып 30 календарь көн эчендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылырга тиеш. Район Башкарма комитеты күрсәтелгән мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру мөмкинлеге булмаган очракта, муниципаль районның рәсми сайтында урнаштырыла.»;

7. 17 статьяда:

7.1. өлеш «Район җирле үзидарәсенең вазыйфаи затларыннан» сүзләреннән соң «инициатив проектларны кертү һәм аларны карау мәсьәләләре буенча фикер алышу,» сүзләрен өстәргә;

7.2. 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Инициатив проектлар кертү һәм аларны карау мәсьәләләре буенча гражданнар җыелышында уналты яшькә җиткән тиешле территориядә яшәүчеләр катнашырга хокуклы. Инициатив проектларны кертү мәсьәләләрен карау һәм тикшерү максатларында гражданнар җыелышын билгеләү һәм үткәрү тәртибе район Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.»;

8. 19 статьяда:

8.1. 2 өлеш түбәндәге эчтәлекле тәкъдим белән тулыландырырга: "Гражданнарның инициативалы проектка ярдәм итү турындагы фикерен ачыклау мәсьәләсе буенча сораштыруда, район яки аның бер өлешендә яшәүче, уналтынчы яшькә җиткән инициативалы төрекем тәкъдим иткәндә катнашырга хокуклы.»;

8.2. 3 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3) район халкы яисә аның бер өлешендә яшәүчеләрдән, аларда уналты яшькә җиткән инициатив проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителә, бу инициатив проектка ярдәм итү турында гражданнарның фикерен ачыклау өчен.»;

8.3. 5 өлештә

8.3.1. Беренче абзацта «Район Советы. Карарда» сүзләрен «Район Советы» сүзләренә алмаштырырга. Гражданнардан сорашып белешү үткәрү өчен муниципаль берәмлекнең рәсми сайты «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә кулланылырга мөмкин. Карарда";

8.3.2. түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

«6) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтыннан файдаланып гражданнардан сораштыру үткәрелгән очракта, сораштыруда катнашучыларны идентификацияләү тәртибе.»;

8.4. 7 өлешнең 1 пунктына «яисә Район халкы» сүзләрен өстәргә;

9. 44 статьяда:

9.1. 1 өлештә:

9.1.1. 3 пунктның унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләрен башкаруны оештыра һәм территориянең карта-планын раслый;»;

9.1.2. 8 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- шәһәр һәм авыл торак пунктларыннан читтәге муниципаль район чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итә;»;

9.1.3. 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« 11) башка вәкаләтләр:

- Район Советы эшчәнлеген тәэмин итә;

- муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару, җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча муниципаль хокукый актлар проектлары буенча фикер алышу өчен массакүләм мәгълүмат чарасын оештыручысы булып тора, муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый һәм мәдәни үсеше турында, аның иҗтимагый инфраструктурасын һәм башка рәсми мәгълүматны муниципаль берәмлек халкына җиткерә;

- җирлекләрнең архив фондларын саклауны да кертеп, муниципаль архивны булдыруны һәм аның эчтәлеген тәэмин итә;

- үз вәкаләтләре чикләрендә федераль законнар нигезендә халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрне гамәлгә ашыра;

- җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларына, район Советы депутатларына, муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренә һөнәри белем һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыра, мәгариф турында Россия Федерациясе законнарында һәм муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә муниципаль хезмәт өчен кадрлар әзерләүне оештыра;

- законнар, әлеге Устав, район Советы карарлары белән расланган район Советы, район Башлыгы яки башка җирле үзидарә органнары вәкаләтләреннән тыш, районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләре буенча бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.;

- муниципаль районның хезмәт күрсәтелә торган административ участогында полиция участок уполномоченные вазыйфасын биләүче хезмәткәргә эш өчен бина бирә;

- 2017 елның 1 январенә кадәр полиция участок уполномоченные вазыйфасын биләүче хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәрнең күрсәтелгән вазыйфа буенча бурычларын үтәү чорына торак урыны бирә;

- 2008 елның 31 декабренә торышы буенча алар карамагындагы югары белем бирү муниципаль мәгариф оешмаларын гамәлгә куючы функцияләрен башкара;

- туризмны үстерү өчен шартлар тудыра;

- адреслау объектларына адреслар тапшыра, муниципаль районның авылара территориясе чикләрендә адресларны үзгәртә, юкка чыгара, мәгълүматны дәүләт адреслар реестрында урнаштыра;

- муниципаль хезмәтләр реестрын төзү һәм алып бару тәртибен билгели;

- кулланучылар хокукларын яклау буенча "Кулланучылар хокукларын яклау турында" 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законында каралган чараларны гамәлгә ашыра;

- участок уполномоченные вазыйфасын биләүче хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына күрсәтелгән вазыйфаны биләгән чорга хезмәткәр торак урыны бирә;

- исерек, наркотик яисә башка токсик исереклек халәтендәге затларга ярдәм күрсәтү чараларын күрә;

- муниципаль янгын сагын төзи.»;

9.2. 44 статьяның 2 өлешендәге 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «3) территориаль планлаштыру, җирдән һәм башка табигый ресурслардан файдалану, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә:

- авыл җирлекләренең генераль планы проектын, авыл җирлекләрен шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен эшли һәм район Советы раславына кертә, аларны гамәлгә ашыруны тәэмин итә;

- җирлек чикләрендә урнашкан җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирә, авыл җирлекләре территорияләрендә түгел урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә, капиталь төзелеш объектларын эксплуатациягә тапшырганда объектлар төзүгә рөхсәт бирә;

- авыл җирлекләре чикләрендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыра;

- җирләрне резервлаштыра һәм авыл җирлекләре чикләрендә муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлекләрен тартып ала;

- Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда биналарны, корылмаларны карый һәм мондый карау барышында ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында тәкъдимнәр бирә;

- муниципаль урман контролен гамәлгә ашыра;

- авыл җирлекләре ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре булдыру өчен кирәкле эшләрне башкаруны тәэмин итә, федераль закон нигезендә ясалма җир кишәрлеге төзү турында шартнамә төзү хокукына ачык аукцион үткәрә;

- комплекслы кадастр эшләрен башкаруда федераль закон нигезендә катнаша;

- авыл җирлекләре территориясендә җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру урыннарын һәм курортларны төзи, үстерә һәм саклауны тәэмин итә, шулай ук җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләрен файдалану һәм саклау өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыра;

- индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын планлаштырыла торган төзү яисә реконструкцияләү турында хәбәрнамәдә индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортын урнаштыруның мөмкин булуы турында хәбәр итә, индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының билгеләнгән параметрларга туры килмәве һәм (яисә) индивидуаль торак төзелеше объектының җир кишәрлегендә бакча йортын урнаштыруның рөхсәт ителмәве турында, төзелгән яисә реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының, бакча йортының индивидуаль торак төзелеше объектларын яисә авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан җир кишәрлекләрендә бакча йортларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе яисә туры килмәве турында белдерү, үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү турында Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә, үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү яисә аны капиталь төзелеш объектларын төзүнең рөхсәт ителгән, реконструкцияләүнең җир белән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата мәҗбүри таләпләргә туры китерү турында карар кабул итә (алга таба шулай ук - билгеләнгән таләпләргә туры китерү), максатчан билгеләнеш буенча файдаланылмый торган яисә Россия Федерациясе законнарын бозып файдаланыла торган җир кишәрлеген алу турындагы карар кабул итә, үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерүне яисә аны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда билгеләнгән таләпләргә туры китерүне гамәлгә ашыра;

- җирлек территориясендә элек исәпкә алынган күчемсез милек объектларының хокук ияләрен ачыклау буенча чаралар күрә һәм үткәрә, күчемсез мөлкәтнең бердәм

дәүләт реестрына кертү өчен күчемсез мөлкәт объектларының хокукка ия булучылары турында белешмәләр җибәрә»;

10. 54 статьяның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«54 статья. Җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм районның шәһәр төзелеше эшчәнлеге комитеты»;

11. 54 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«54 статья. Районның җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге комитеты.

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге комитеты (алга таба - Комитет) үз вәкаләтләре чикләрендә хуҗалык җәмгыятьләренең устав капиталларында муниципаль милек, җир кишәрлекләре, акцияләр, өлеш белән идарә итүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарәсенең даими эшләүче органы булып тора, шулай ук шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә идарә итү функцияләрен гамәлгә ашыра.

Җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге комитеты район Советы алдында хисап тотарга бурычлы.

2. Җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге комитеты рәисе район Башлыгы тәкъдиме белән район Советы тарафыннан билгеләнә.

3. Җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге комитеты рәисе район җирле үзидарәсенең вазыйфаи заты булып тора, җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге комитеты эшчәнлегенә җитәкчелек итә һәм аның эшен оештыра.

4. Җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге комитетының үз исеме булган мөһер, бланклары бар.

5. Җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге комитеты эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнары район бюджетында Россия Федерациясе бюджетлары чыгымнары классификациясе нигезендә аерым юл белән карала.

6. Җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге комитеты үз эшчәнлеген законнар, әлеге Устав һәм Җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре комитеты турындагы нигезләмә нигезендә, Район Советы раслый торган документ нигезендә гамәлгә ашыра.»;

12. 60 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы район Советы депутатына, башка вазыйфаи затларга бирелә торган социаль һәм башка гарантияләр «Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең вәкиллекле органы депутаты, сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм район Советы карарлары белән билгеләнә.

2. Район Советы депутатына үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыру өчен, тулаем алганда аена алты эш көненнән дә артык булмаган чорда эш урынын (вазыйфасын) саклап калу гарантияләнә»;

13. 69 статьяның 4 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:
«3) гадәттән тыш хәлләр режимы гамәлдә булган чорда табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү максатларында эшләнгән норматив хокукый акт проектлары.»;

14. 82 статьяда:

14.1. 12 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

14.2. 12.1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12.1. Тиешле бюджет керемнәренең гомуми күләмен үзгәртүгә китерә торган район Советының муниципаль хокукый актлары нигезләмәләре, агымдагы финанс елына һәм план чорына бюджет кабул ителү турында район Советына карар кертелгәннән соң, агымдагы финанс елы һәм план чоры бюджетына үзгәрешләр керткәндә чираттагы финанс елында исәпкә алына.»;

15. түбәндәге эчтәлекле 85.1 статья өстәргә:

«85.1. Инициатив проектларны гамәлгә ашыруны финанс ягыннан һәм башкача тәэмин итү

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 26.1 статьясында каралган инициатив проектларны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү чыганагы булып, муниципаль берәмлекнең тиешле чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан инициатив түләүләр һәм (яисә) бюджетара трансфертлар күләмнәрен исәпкә алып, инициатив проектларны гамәлгә ашыруга җирле бюджет турындагы карар белән каралган бюджет ассигнованиеләре тора.

2. Инициатив түләүләр дигәндә, конкрет инициативалы проектларны гамәлгә ашыру максатларында Россия Федерациясе законнары нигезендә ирекле нигездә түләнә торган һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә җирле бюджетка күчерелә торган гражданнарның, индивидуаль эшкуарларның һәм төзелгән юридик затларның акчалары күздә тотыла .

3. Инициатив проект гамәлгә ашырылмаган очракта, инициатив түләүләр аларны җирле бюджетка күчергән затларга (шул исәптән оешмаларга) кайтарылырга тиеш. Инициатив проектны гамәлгә ашыру йомгаклары буенча инициатив проектны гамәлгә ашыру максатларында файдаланылмаган инициатив түләүләрнең калган өлеше барлыкка килгән очракта, күрсәтелгән түләүләр аларны җирле бюджетка күчергән затларга (шул исәптән оешмаларга) кайтарылырга тиеш.

Җирле бюджетка күчергән затларга (шул исәптән оешмаларга) кире кайтарылырга тиешле инициатив түләүләр суммаларын исәпләү һәм кире кайтару тәртибе район Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

4. Инициатив проектларны гамәлгә ашыру, шулай ук, кызыксынган затларның ихтыярый һәм төрле эштә катнашуы рәвешендә дә тәэмин ителергә мөмкин.»;

16. 92 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Район Уставы, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында район Советы карары дәүләт теркәве узганнан соң рәсми басылып чыгарга тиеш һәм рәсми бастырып чыгарганнан соң үз көченә керә.

Район Башлыгы теркәлгән район Уставын, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында район Советы карарын, муниципаль берәмлекләр Уставларын теркәү өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре уставларының дәүләт реестрына үзгәрешләр кертү хакында муниципаль хокукый актын, район Уставына өстәмәләр кертү турында белешмәләрне «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясы 6 өлешендә каралганча, территориаль органыннан район Уставы турында белешмәләр кертелгән көннән соң, җиде көн эчендә бастырып чыгарырга тиеш.

| | |
|---|---|
| Муниципаль  район Башлыгы | Т.Д. Нагуманов |